**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,58

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay.ispolkom@tatar.ru сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2022 елның 27 декабре 478№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 маендагы «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 164 карарына үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 30 июлендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 60-ЗРТномерлы, 2020 елның 24 апрелендәге «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 17 – ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законнары нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 маендагы «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 164 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарга кушымтаны, әлеге карарга кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.2. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә Татарстан Республикасы КоАП 2.18, 2.19, 2.20 статьяларын кертергә;

1.3. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегеннән түбәндәге 2.8, ст. юкка чыгарырга;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга, Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: Р.Х.Морадымов

Әлки муниципаль районы Башкарма
комитетының 2022 елның 27 декабрендәге
478 номерлы карарына кушымта

Үз компетенциясе кысаларында ТР Административ хокук бозулар кодексының ( ТР АХБК) (2020 елның 26 октябреннән гамәлдә) 2.1, 2.4-2.7, 2.12-2.13, 2.15 ст. 2 өлеш, 2.17, 2.18, 2.19, 2.20, 3.2-3.6, 3.10, 3.11, 3.14, 3.15, 3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 ст. каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге.

| ТР АХБКның статьясы. | Вәкаләтле вазыйфаи зат |
|---|---|
| Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын бозу (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма элмә такталарын үз исеме һәм элмә тактасы урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматлар күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата) ТР АХБКның 2.1 статьясы.<br>Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр ТР АХБКның 2.4 статьясы<br>Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яки тагу ТР АХБКның 2.5 статьясы<br>Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү ТР АХБКның 2.6 статьясы<br>Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларыннан файдалану тәртибен бозу ТР АХБКның 2.7 статьясы | Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br><br>Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше буенча бүлек начальнигы; |
| Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен бозу. Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен бозу, шулай ук гражданнарны исәпкә куюда яисә гражданнарны исәпкә алудан хокуксыз баш тартуга китергән күрсәтелгән исәпкә алуны алып бару тәртибен бозу ТР АХБКның 2.12 статьясы<br>Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу һәм исәп алып бару | - Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы; |

| | |
|---|---|
| тәртибен бозуТР АХБКның 2.13 статьясы | |
| Террорчылыкны профилактикалау, аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару буенча коллегиаль органның карарын үтәмәү яисә бозу 2.15 статьясындагы 2 өлеше | -Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары; |
| (COVID-19) яңа коронавирус йогышы таралуны булдырмый калуга һәм бетерүгә юнәлдерелгән ТР норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү ТР АХБКның 2.17 статьясы | -Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары;<br><br>- Әлки муниципаль районы җәмәгать тәртибен саклау пункты эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгеч;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлек юнәлеше буенча әйдәп баручы белгеч. |
| Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе карарын яисә күрсәтмәсен үтәмәү ТР АХБКның 2.18 статьясы<br>Балигъ булмаганнарга тонусны күтәрә торган алкогольсез эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итү ТР АХБКның 2.19 статьясы<br>Балигъ булмаганнарга гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары кирәкле булган сыекландырылган углеводород газлы товарларны ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны сыекландырылган углеводород газын сулап куллануга җәлеп итү ТР АХБКның 2.20 статьясы | - Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм административ практика секторының әйдәп баручы белгече;<br>- Әлки муниципаль районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы сәркатибе |
| Урам сәүдәсен оештыру тәртибен бозу | - Әлки муниципаль районы Башкарма |

| | |
|---|---|
| ТР АХБКның 3.2 статьясы | комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары;<br><br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы. |
| Җир асты коммуникацияләрен тоту кагыйдәләрен бозу ТР АХБКның 3.3 статьясы<br>Урам, квартал эчендә яктырту кагыйдәләрен бозу ТР АХБКның 3.4 статьясы<br>Тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу ТР АХБКның 3.5 статьясы<br>Авыл җирлекләре һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрне бозу. Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрне бозуТР АХБКның 3.6 ст | - Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары;<br><br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мобилизация эшләре буенча ярдәмчесе;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы. |
| Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен бозу ТР АХБКның 3.10 ст. | - Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы; |
| Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итүгә карата таләпләрне бозу ТР АХБКның 3.11 ст.<br>Мәдәни-тамаша чараларында булганда җәмәгать тәртибен бозу ТР АХБКның 3.14 статьясы<br>Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү ТР АХБКның 3.15 статьясы | - Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары;<br><br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт | - Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура |

| | |
|---|---|
| мәйданчыкларында, хайваннарны урамда йөртү мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру ТР АХБКның 3.17 статьясы | үсеше буенча урынбасары;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече |
| Муниципаль милектә булган торак булмаган фонд объектлары белән эш итү һәм әлеге объекттан файдалану тәртибен бозуТР АХБКның 4.4 статьясы | - Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече;<br>- Әлки муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе. |
| Билетсыз йөрү ТР АХБКның 5.1 статьясы<br>Багаж ташу кагыйдәләрен бозу ТР АХБКның 5.2 статьясы<br>Пассажирны йөртүдән баш тарту (муниципаль пассажирларга карата) ТР АХБКның 5.6 статьясы | - Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы;<br>- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече; |